РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2018 № 23

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.11.2003 ел №131-ФЗ, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм шулай ук төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуның бердәм таләпләрен булдыру, җирлек биләмәсендә төзекләндерүнең дәрәҗәсен күтәрү максатында, Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 ноябрендә кабул ителгән 25 нче номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” расланган карарына әлеге карарның кушымтасы белән килештереп, Шәмәрдән авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны “Интернет”мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 24.09.2018 елның №23 карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр**

**1**. 6 нчы пунктта:

1.1. икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“архитектур яктырту- әлеге кагыйдәләр белән күздә тотылган очракларда, җирлек биләмәсендә урнашкан биналарны, корылмаларны, бина комплексларын, мәдәни мирас объектларын, төзекләндерү элементларын, артитектур-ландшафт объектларын караңгылыктан ачыклап һәм образлы итеп күрсәтү өчен һәм кичке вакытта сәнгати-тәэсирле визуаль мохит формалаштыру өчен кулланыла”;

1.2. бишенче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“биләмәне төзекләндерү –гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итү һәм үстерүгә, җирлек биләмәсенең санитар һәм зәвык хәлен яхшырту һәм саклап тоту, торак пунктларның биләмәләрен һәм анда урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми кулланылыштагы биләмәләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, аларның тирә-юнен саклап тотуга юнәлтелгән, әлеге кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру эшчәнлеге;

1.3. уникенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“декоратив-монументаль сәнгать – ул төзекләндерү элементлары, шул исәптән декоратив-сәнгати бизәү кулланып ясалган гомумкулланылыштагы биләмәләр, массакүләм чаралар өчен билгеләнгән биналар һәм корылмалар өчен кече архитектура формалары;

“декоратив-сәнгати бизәү – объектның имиджын һәм сәнгатьлелелген күтәрүгә тәэсир итүче декоратив-монументаль сәнгатьнең монументаль яисә декоратив скульптура төрендә, монументаль яки декоратив сынлы сәнгать, мурал, мозаика, орнамент, стрит-арт, инсталляция, барельеф, сәнгати металл һәм башка төрләр.

1.4. уналтынчы абзацны алып атырга;

1.5. утыз алтынчы абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“объектның архитектур яктыртылыш паспорты- җирлек биләмәсендә урнашкан һәм аларның тышкы бизәлешенә таләпләр урнаштыручы, аерым торучы биналар яки корылмаларның, биналар комплексының, мәдәни мирас объектларының, төзекләндерү элементларының, архитектур-ландшафт объектларының бәйрәмчә яктыртылышын да исәпкә алган, бердәм архитектур-сәнгати яктыртылышны билгеләүче, билгеләнгән тәртиптә килешенгән документ;”

1.6. утыз җиденче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“биналар һәм корылмаларның, шул исәптән капиталь булмаган (фасадларның төсле чишелеше) колористик чишелеш паспорты – бердәм архитектур һәм фасадларның төсе чишелешен (фасад элементларын да кертеп) билгеләүче, аның тышкы бизәлешенә таләпләр куючы, билгеле тәртиптә килешенгән документ”;

1.7. кырыгынчы абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“якын-тирәдәге биләмә – бинага, корылмага, җир кишәрлегенә, әгәр ул җир кишәрлеге барлыкка килгән һәм аның чикләре җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән, ТР закон таләпләренә туры килгән очракта, якын тирәдәге гомумкулланылыштагы җир;

1.8. кырык җиденче абзацта “биналарны бизәү” сүзен “һәм корылмаларны, шул исәптән капиталь булмаганнарны да” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.9. илленче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

“күрсәткечләр – урам исемнәре, йорт, подъезд, фатир номерлары, янгын гидрантлары күрсәткечләре, геодезик билгеләр, магистраль камералары һәм суүткәргечләрнең коелары, канализация, җир асты газүткәргечләре корылмалары, полигонометрик билгеләр, инвалидлар өчен билгеләр, җирлек турында гомуми мәгълүмат бирүче, туризм өлкәсе объектларының урнашуы, мәгариф объектлары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында язылган аерым язулар;”

Урамнар һәм гомумшәһәр юллары – торак пункт эстетикасына югарырак таләпләр куелган гомумкулланылыштагы биләмәләр. Урамнарның һәм гомумшәһәр юлларының исемлеге җирлекнең муниципаль хокукый акты белән раслана.”

1.10. илле алтынчы абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“төзекләндерү элементлары – декоратив, техник, планлаштыручы, конструктив төзелешләр, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлау һәм бизәү төрләре, (шул исәптән биналарның, корылмаларның фасадларын), кече архитектура формалары, стационар булмаган объектлар, тышкы мәгълүмат урнаштыру чаралары һәм биләмәнең төзекләндерү өлеше буларак кулланылучы күрсәткечләр.”

**2**. Беренче абзацның 9 нчы пунктында “тормышка ашырырга тиешләр” сүзен “тормышка ашыралар” сүзе белән алыштырырга.

**3**. Икенче абзацның 17 нче пунктында:

3.1. “өчен җаваплылыкны” сүзен алып атырга;

3.2. “алып баралар” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**4**. 25 нче пунктта:

4.1. беренче абзацта “төзелмә” сүзен алып атырга;

4.2. 7 нче пунктчада “колонна” сүзе алдыннан “декоратив-сәнгати бизәлеш элементлары” сүзен өстәргә;

**5**. 26 нчы пунктта “тиешләр” сүзен алып атырга;

**6**. 26.1. һәм 26.2 пунктларында “чистартырга һәм юдырырга” сүзләрен “чистарталар һәм юдыралар” сүзләре белән алыштырырга;

**7**. 26.3. пунктта “үткәрергә” сүзен “үткәрәләр” сүзе белән алыштырырга;

**8**. 26.4 пунктта:

8.1. беренче абзацта “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга;

8.2. икенче абзацта “уздырылырга тиеш” сүзен “уздырыла” сүзе белән алыштырырга.

**9**. 26.5. пунктта “башкарырга” сүзен “башкаралар” сүзе белән алыштырырга.

**10**. 26.6 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“26.6. тышкы мәгълүмат кую чарасын (элмә тактаны) , ул кулланылмаган очракта (арендатор(субарендатор) киткән), бинаның фасады үзгәргән очракта алып аталар”.

**11**. 27.8 пунктта “яки төзелмәләр” сүзен алып атырга.

**12**. 27.11 пунктта “буяу” сүзен “бизәк төшерү” сүзе белән алыштырырга.

**13**. 27.13 пункттан соң түбәндәге эчтәлектәге 27.13.(1) пункты өстәргә:

“27.13(1). Фриз урнаштыру, фасадны конструкциягә (каркас, фасад, стеналар) күренә торган беркетү элементлары белән бизәү, һәм шулай ук мондый беркетүләрне каплый торган тоташтыру (планка, почмаклар, профильләр), фризның, кыекның, бизәлешнең төсенә туры килми торган төс белән бизәү”.

**14**. 27.22 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“27.22. биналарның һәм корылмаларның, шул исәптән капиталь булмаган биналарның фасадларында, тәрәзәләрдә(шул исәптән эчке ягында да), ишекләрдә (шул исәптән эчке

ягында да) алга таба куллану максаты белән афишалар, белдерүләр, плакатлар һәм башка төрле мәгълүмати-басма әйберләрне элү һәм ябыштыру”.

**15**. 27.23 пунктта “биналарның фасадларына граффити төшерү” сүзен “фасадларның архитектур, төсле чишелешен, биналарның декоратив-сәнгати бизәлешен һәм” сүзе белән алыштырырга.

**16**. 28.5 пункттан соң түбәндәге эчтәлектәге 28)1) пункты өстәргә:

“28(1) тышкы кондиционерлар урнаштыру:

- Торак пунктның зәвыгына югарырак таләпләр куелган урам һәм гомумшәһәр юллары ягындагы төп һәм ян стеналарга;
- Кондиционерның эчке һәм тышкы блогын тоташтыручы чыбыктан еракта;
- Конденсатны үзәкләштерелгән читкә җибәрүдән башка”.

**17**. 30 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“30. Рөхсәт ителә:

30.1. подъездларга керү урынында мәгълүмат стендлары урнаштыру;

30.2. проектка туры китереп, биналарның түбәләрендә телевидение антенналары һәм кабельләре урнаштыру;

30.3. тышкы кондиционерларны проект белән махсус каралган яки күзгә артык чалынып тормый торган урыннарга(балкон, лоджияләрнең эчке як стеналарына) кую шарты белән, торак пунктның зәвыгына югарырак таләпләр куелган урам һәм гомумшәһәр юллары ягындагы төп һәм ян стеналарга урнаштыру.

**18**. “Йорт билгеләре” бүлеген “Күрсәткечләр” исеме белән алыштырырга.

**19**. 31-39 пунктларны түбәндәгечә бәян итәргә:

“31. Биналарның, корылмаларның фасадлары күрсәткечләр белән җиһазландырылган булырга тиеш.

32. Урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр Башкарма комитетның муниципаль норматив актлары һәм әлеге кагыйдәләр белән беркетелгән урыннарда һәм башкаруда куела.

33. Урам исемнәре һәм йорт номерлары турында мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә языла.

Урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрнең төренә һәм үрнәгенә таләпләр авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль норматив актлары белән раслана.

34. Урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр фасадларда:

- 2,5 метрдан түбән булмаган һәм җир өстеннән 5,0 метрдан да биек булмаган урында;
- фасадның тышкы почмагыннан 1,0 метрдан ерак булмаган;
- витрина, тәрәзә, архитектур детальләр һәм декоратив-сәнгати бизәлешне капламый торган;
- ачык җайланмалы яктырткыч кулланмыйча;
- фасадның архитектур үзенчәлекләрен исәпкә алып;
- төп һәм ян фасадта- фасадның уң ягында, әлеге кагыйдәләрдә каралган искәрмәләрдән тыш;
- ишегалды фасадында –квартал эченә керү ягында;
- транспортның бер яклы йөрешле урамнарда –транспорт хәрәкәтенең башлану өлешенә якын фасадта;
- фасадның озынлыгы 100 метрдан артса, фасадның сул ягында да;
- сәнәгать предприятиеләренең корпусларында яки коймаларында – төп керү юлының уң ягында;

- урам һәм гомумшәһәр юллары киселешенә караган фасадларда – фасадның урам киселешенә якынрак почмакларында;

- бердәм горизонталь һәм вертикаль күчәрне исәпкә алып урнаштырыла.

35. Аерым басып торучы күрсәткечләрне (стелаларны) урнаштыру рөхсәт ителми:

- нейтраль булмаган төсләрдә(соры, кара, көрән һәм башка караңгы төсләр) һәм (яки) табигый булмаган(табигыйга ошаган) материаллардан эшләнсә;

- 6,0 метрдан артык биеклектә;

- фундамент казымыйча;

- тротуарның норматив киңлеген тарайтуга китергән очракта, шулай ук автомобильләрнең үтеп китү, куеп тору урыннарына;

- агач кәүсәләренә 5,0 метрдан якынрак фундамент казып, җир кишәрлеге чикләрендә проект белән каралган яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

- профнастилдан, тукымалардан ясаганда ачык беркетү ысуллары кулланып;

- мәгълүмат кырында фоторәсем кулланып;

- машина кую урыннары саны турында мәгълүмат бирү очрагыннан тыш, мәгълүмат бирүгә динамик ысул куллану;

36. Подъездлар һәм фатир номерлары язылган күрсәткечләр ишек кысасы өстендә яки ишек кысасының уң ягында 2,0-2,5 метр биеклектә куела.

37. Янгын гидрантлары, полигонометрик билгеләр, геодезик билгеләрнең урнашу урыны күрсәткечләре биналарның цоколендә, магистраль камераларында һәм суүткәргеч һәм канализация челтәрләренең коеларында урнаштырыла.

38. Янгын гидрантлары, полигонометрик билгеләр, геодезик билгеләрнең урнашу күрсәткечләрен урам исемнәре, йорт номерлары белән рәттән, шулай ук архитектур детальләр, декоратив-сәнгати бизәлеш, пыялалар, капкалар, ишекләрдә урнаштыру рөхсәт ителми.

39. Күрсәткечләрне чиста һәм төзек хәлдә тоту мөхим.

**20**. 40-42 пунктларны алып атырга.

**21**. 43 пунктның беренче абзаөында “пандуслар, култыксала һ.б.” сүзләреннән соң “чүп савытлары белән” сүзе белән тулыландырырга.

**22**. 44 пунктта “проектлаганда” сүзеннән соң “эксплуатаөияләгәндә” сүзен өстәргә.

**23**. 44.5 пунктында “0,5 м дан артыграк” сүзен алып атырга.

**24**. 52 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 нчы пунктча өстәргә:

9) ачык люклар, юл катлавындагы зыяннарны ачыклау һәм коймалар урнаштыру максатында юлларның торышын көндәлек күзәтеп тору;”

**25**. 55 пунктта “бурычлы” сүзен алып атырга.

**26**. 55.1 пунктта:

26.1. “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга;

26.2. “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.

**27**. 55.2 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

“55.2 торак йортта урам исеме һәм йорт номеры күрсәткечен булдыралар һәм аны төзек хәлдә тотуны тәэмин итәләр”.

**28**. 55.3 пунктта “кертергә” сүзен “кертәләр” сүзе белән алыштырырга.

**29**. 55.4 пунктта:

29.1. “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга;

29.2. “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**30**. 55.5 пунктта:

30.1. “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга;

30.2. “үткәрү” сүзен “үткәрәләр” сүзе белән алыштырырга;

30.3. “юл куймаска” сүзен “юл куймыйлар” сүзе белән алыштырырга.
**31**. 55.6 пунктта:
31.1. “сафландырырга” сүзен “сафландыралар” сүзе белән алыштырырга;
31.2. “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.
**32**. 55.7 пунктта “җыештырып куярга” сүзен “җыештырып куялар” сүзе белән алыштырырга.
**33**. 55.8 пунктта:
33.1. “җиһазларга” сүзен “җиһазлыйлар” сүзе белән алыштырырга;
33.2. “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**34**. 55.9 пунктт “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**35**. 55.10 пунктта “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.
**36**. 56.7 пунктта “сулыкларны пычратырга” сүзен алып атырга.
**37**. 69 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
“69. Яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең техник яктан төзек халәте (шул исәптән люкларны, рәшәткәләрне вакытында ябу) аларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан тәэмин ителә.”
**38.** 74 пунктта “карап торырга тиеш” сүзен “карап торалар” сүзе белән алыштырырга.
**39**. 76 пунктта:
39.1. беренче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:
“76. Урамнар, юллар, мәйданнар, җәяүле тротуарлар, торак кварталлар, ишегаллары, предприятие, учреждение, оешмаларның биләмәләре, шулай ук урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр, юл билгеләре һәм күрсәткечләре, тышкы мәгълүмат чаралары һәм витриналар тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.”
39.2. өченче абзацта:
39.2.1. “аншлаглар һәм йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган күрсәткечләр” сүзләрен “урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләре” сүзләре белән алыштырырга;
39.2.2. “архитектур-сәнгатьчә яктырту” сүзен “тышкы мәгълүмат чараларын архитектур яктырту” сүзе белән алыштырырга.
**40**. 77 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
“77. Торак пунктның панорамасын, гомумкулланылыштагы биләмәләрне формалаштыручы, фасадлары белән торак пунктның зәвыгына югарырак таләпләр куелган урамнарга һәм юлларга караган биналар һәм корылмаларның милекчеләре милек формасына карамыйча:
- билгеләнгән тәртиптә килешенеп, проектка(паспортка) туры китереп, архитектур-ландшафт объектларының, төзекләндерү элементларының, биналар комплексының, аерым торучы бина яки корылмаларның бәйрәмчә яктыртылуын да кертеп, архитектур яктырту булуы һәм функциясен;
- архитектур һәм бәйрәмчә яктырту өчен кулланылучы яктырту җайланмаларының экономияле һәм энергоэффектив булуын, электр энергиясен рациональ бүлү һәм куллануны;
- яктырткыч җайланмаларның зәвыгы, дизайны, аларны көндез һәм төнлә кабул итүне исәпкә алган материаллар һәм эшләнмәләрнең сыйфаты;
- яктырткыч җайланмаларның төрле режимда эшләве белән идарә итүнең һәм хезмәт күрсәтүенең уңайлылыгын тәэмин итәләр.

Архитектур яктыртуга таләпләр, бәйрәмчә яктыртуны да исәпкә алып, авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары, күрсәтелгән кагыйдәләр белән билгеләнә.”
**41**. 84 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“84. Яктырту баганаларына һәм җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре баганаларына куелган барлык элементлар һәм объектларның канәгатьләнерлек тышкы кыяфәтен һәм төзек, куркынычсыз халәтен аларның милек хуҗалары тәэмин итә”
**42**. 87 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.
**43**. 87.1 пунктта
43.1. “күзәтергә” сүзен “күзәтәләр” сүзе белән алыштырырга;
43.2. “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**44**. 87.2 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
“87.2. яктыртуны кушуны һәм аеруны, шул исәптән архитектур яктыртуны һәм тышкы мәгълүмат чараларын яктыртуны, куелган тәртипләргә туры китереп башкаралар.”
**45**. 87.3 пунктта “сакларга” сүзен “саклыйлар” сүзе белән алыштырырга.
**46**. 87.4 пунктта “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**47**. 88 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
“88. Тротуарларга урнашкан тышкы яктырту баганалары һәм мачталарының һәм җәмәгать транспортының контакт челтәре баганаларының әйләнә-тирәсен җыештыруны тротуарларны җыештырырга җаваплы затлар тәэмин итә.
Автомат режимда эшләүче трансформатор һәм бүлү подстанцияләренә, башка инженер корылмаларына якын биләмәләрне җыештыруны шул объектлар урнашкан җир хуҗалары тәэмин итә.”
**48**. 89 пунктта “монументаль-декоратив бизәлеш” сүзен “декоратив-сәнгати бизәлеш (скульптура, аерым басып торучы инсталляцияләр, стрит-арт), аерым торучы күрсәткечләр (стелы)” сүзләре белән алыштырырга”.
**49**. 91 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.
**50**. 91.1 пунктта “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга.
**51**. 91.2 пунктта:
51.1. “чор” сүзеннән соң “җитештерәләр” сүзен өстәргә;
51.2. “җитештерергә” сүзен алып атырга.
**52.** 91.3 пунктта “чистартырга” сүзен “чистарталар” сүзе белән алыштырырга.
**53**. 91.4 пунктта:
53.1. “урнаштырырга” сүзен “урнаштыралар” сүзе белән алыштырырга;
53.2. “үзгәртергә” сүзен “үзгәртәләр” сүзе белән алыштырырга.
**54**. 91.5 пунктта “күзәтергә” сүзен “күзәтәләр” сүзе белән алыштырырга.
**55**. 91.6 пунктта “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**56**. 94 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
“94. Җир кишәрлеген арендалау срогы чыкканнан соң, аредатор тарафыннан стационар булмаган объект сүтеп алына, ә җир кишәрлеге азат ителә һәм беренчел халәтенә кайтарыла.”
**57**. 95 пунктны алып атырга.
**58**. 96 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.
**59**. 96.1 пунктта “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.
**60**. 96.2 пунктта:
60.1 “күзәтергә” сүзен “күзәтәләр” сүзе белән алыштырырга.
60.2 “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга.
**61**. 96.3 пунктта:
61.1. “анысларга” сүзен “аныклыйлар” сүзе белән алыштырырга;
61.2. “чистартырга” сүзен “чистарталар” сүзе белән алыштырырга;
61.3. “буярга” сүзен “буйыйлар” сүзе белән алыштырырга.
**62**. түбәндәге эчтәлекле 96.4 пункты өстәргә:

“96.4. тышкы мәгълүмат чараларын, билгеләнгән тәртиптә килешенеп эшләнгән объектның проекты (паспорты) нигезендә, стационар булмаган объектка урнаштыралар һәм эксплуатациялиләр.”

**63**. 109 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.

**64**. 109.1 пунктта “билгеләргә” сүзен “билгелиләр” сүзе белән алыштырырга.

**65**. 109.2. пунктта:

65.1. “күзәтергә” сүзен “күзәтәләр” сүзе белән алыштырырга;

65.2. “чистартырга” сүзен “чистарталар” сүзе белән алыштырырга.

**66**. 109.3 пунктта “юл куймаска” сүзен “юл куймыйлар” сүзе белән алыштырырга.

**67**. 109.4 һәм 109.5 пунктларда “җиһазларга” сүзен “җиһазлыйлар” сүзе белән алыштырырга.

**68**. 109.6 һәм 109.7 пунктларда “юл куймаска” сүзен “юл куймыйлар” сүзе белән алыштырырга.

**69**.109.8 пунктта “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга.

**70**. 109.9 пунктта:

70.1. “үткәререргә” сүзен “үткәрәләр” сүзе белән алыштырырга;

70.2. “урнаштырырга” сүзен “урнаштыралар” сүзе белән алыштырырга;

70.3. “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**71**. 109.10 пунктта “җиһазларга” сүзен “җиһазлыйлар” сүзе белән алыштырырга.

**72**. 109.11 пунктта:

72.1. “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга;

72.2. “бүлергә” сүзен “бүләләр” сүзе белән алыштырырга.

**73.** “Авыл җирлеге биләмәсен бәйрәмчә бизәү” бүлегенең исемен “Җирлек биләмәсен бәйрәмчә (вакыйгалы) бизәү” дип үзгәртергә.

**74**. 110 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“110. “Җирлекнең биләмәсен бәйрәмчә (вакыйгалы) бизәү истәлекле вакыйгалар, мәдәни, спорт чаралары белән бәйле дәүләт яки башка бәйрәм чараларын уздыру вакытында башкарыла.

Бәйрәмчә (вакыйгалы) бизәү мероприятиеләргә бәйле рәвештә афишалар, паннолар, декоратив элементлар һәм композицияләр урнаштырудан, шулай ук бәйрәмчә яктырткычлар (гирляндалар, күләмле яктырткыч композицияләр һ.б. ) урнаштырудан гыйбарәт. Бәйрәмчә (вакыйгалы) бизәү конструкцияләре биналарның фасадларына яки аерым куелырга мөмкин.

Бәйрәмчә (вакыйгалы) бизәү элементларын әзерләгәндә һәм урнаштырганда юл хәрәкәтен көйләүче техник чараларның күренүчәнлеге начарлануы, бозылуы рөхсәт ителми.”

**75**. “Җирлек биләмәсен бәйрәмчә бизәү” бүлегеннән соң “Җирлек биләмәсендә йорт хайваннарын һәм кошларын тоту” бүлеген һәм түбәндәге эчтәлекле 110.1 пункт өстәргә:

“Җирлек биләмәсендә йорт хайваннарын һәм кошларын тоту.

110.1. Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту:

110.1.1. Йорт хайваннарын тотуның, этләрне йөртүнең шартлары, төп принциплары Татарстан Республикасының 07.03.2014 №16-ЗРТ “Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым сораулары турында” законы белән билгеләнә.

110.1.2. Авыл хуҗалыгы хайваннарын квартира, кунакханә тибындагы торак йортларда, тулай торакларда тоту рөхсәт ителми.

110.1.3. Авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү, җирлек башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән махсус көтүлек урыннарында, хуҗасы яки вәкаләтле зат күзәтүе астында башкарыла.

110.1.4. Рөхсәт ителми:

110.1.4.1. хайваннарны балалар мәйданчыкларына, мәктәп, балалар бакчасы биләмәләренә, ашханәләргә, шифаханәләргә, азык-төлек кибетләренә кертү;

110.1.4.2. тыелган билге булган очракта хайваннарны учреждениеләргә кертү;

110.1.4.3. хайваннарны һәм кошларны күзәтүчесез торак пункт биләмәләренә чыгару;

110.1.4.4. авыл хуҗалыгы хайваннарын башкарма комитет тарафыннан билгеләнмәгән җирләрдә көтү;

110.1.4.5. хайваннарны исерек хәлдәге затлар яки 14 яше тулмаган затлар көтү;

110.1.4.6. йорт хайваннарын һәм кошларны балконда, лоджиядә, торак йортларның гомумкулланылыштагы урыннарында (чиктәш фатирларның коридорында, баскыч клеткаларында, чормада, подвалда һ.б. ярдәмче бүлмәләрдә) даими тоту;

110.1.4.7. йорт хайваннарының, махсус мероприятиеләр үткәрү өчен билгеләнгән урыннардан тыш (күргәзмә һ.б.), биләмәдәге торак пунктларда махсус билгеләнмәгән урыннарда булуы;

110.1.5. этне йөртү өчен махсус билгеләнгән урында гына бәйдән ычкындырырга мөмкин. Махсус билгеләнгән урын булмаган очракта, башкарма комитет тарафыннан норматив-хокукый документ белән билгеләнгән сөзәклекләрдә, буш урыннарда этләрне йөртү рөхсәт ителә.

110.1.6. Этләрне өйрәтү яхшылап әйләндереп алынган мәйданчыкларда яки торак пункттан читтә генә башкарылырга мөмкин.

110.1.7. Йорт хайваннары яки кошлары тарафыннан килгән зыян өчен, РФ гамәлдәге законнары тәртибендә, аларның хуҗалары җавап тота.

110.1.8. Җәмәгать урыннарында күзәтүчесез йөрүче хайваннар тотылырга тиеш.

**76**. 118.4 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“118.4. Тротуарлардан, ишегалларыннан җыештырып алынган, калдык-постыклар, химик реагентлар, ком-тоз катнашмалары белән пычранмаган чиста көпшәк карны яшеллекләргә зыян китермичә һәм эрегән суларның агып китүенә тоткарлык тудырмыйча, яшел зоналарга чыгару рөхсәт ителә.”

**77**. 121 пунктта “үз исәбеннән үткәрергә бурычлы” сүзе урынына “үз исәбеннән үткәрәләр” сүзе белән алыштырырга.

**78**. 141.2 пунктта “ике урна” сүзе алдына “бертөрле формадагы һәм төстәге” сүзләрен өстәргә.

**79**. 143.6. пунктта “тәэмин итәргә бурычлылар” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**80**. 147.6. пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“147.6. Ишегалларыннан һәм кварталара йөрү юлларыннан җыелган, куллану калдыклары, ком-тоз катнашмалары һәм реагентлар белән пычранмаган чиста карны, яшеллекләрне саклау һәм эрегән кар сулары агу мөмкинлеге тәэмин ителгән очракта, яшел зоналарга кую рөхсәт ителә.”

**81**. 15 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.

**82**. 151.1. пунктта “якларга” сүзен “яклыйлар” сүзе белән алыштырырга.

**83**. 151.2 пунктта “урнаштырырга” сүзен “урнаштыралар” сүзе белән алыштырырга.

**84**. 152 пунктта “тәэмин итәргә бурычлылар” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**85**. 153.5 пунктта “йорт яны территорияләрен” сүзләрен “шул исәптән шлагбаумнар яки үтәлисез йөрү яки үтеп китү өчен автомат капкалар” сүзләре белән тулыландырырга.”

**86**. түбәндәге эчтәлекле 153.16 пункт өстәргә:

“153.16. транспорт чараларын, шул исәптән чәчелеп ятучы(төзек булмаганнарын), кайсы ел фасылы булуга карамастан, әлеге территорияләрдә мәҗбүри төзекләндерү эшләрен башкару зарурлыгы булу очракларыннан тыш, яшел территорияләргә, балалар, спорт, хуҗалык мәйданчыкларына кую.”

**87**. 155 пунктта “тәэмин итәргә бурычлылар” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**88.** 155.1 пунктта “сакланыш” сүзен “бөтенлек” сүзе белән тулыландырырга.

**89**. түбәндәге эчтәлекле 155.5 пункты өстәргә:

“155.5. яшелләндерелгән территорияләрне саклау элементларын, транспорт чаралары кермәслек итеп, 0,5 м биеклектән артмаган декоратив коймалар яки 0,5 м биеклектән артмаган баганалардан урнаштырырга яки куаклар утыртырга.”

**90**. 165 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“165. Төзекләндерүнең түбәндәге элементлары проект (паспорт) нигезендә, билгеләнгән тәртиптә килешенеп һәм тулаем аңа туры китереп урнаштырыла:

- аерым торучы күрсәткечләр(стелалар);
- тышкы мәгълүмат чаралары;
- декоратив-сәнгати бизәү төрендәге кече архитектур формалар, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү, су җайланмалары, типлы муниципаль җиһаз, коммуналь-көнкүреш җиһазлары;
- капиталь булмаган объектлар, шул исәптән шәхси башкарудагы сезонлы объектлар, һәм стационар булмаган сәүдә объектлары;
- аерым витриналар һәм керү төркемнәреннән тыш, биналарны, корылмаларны архитектур яктырту, шул исәптән капиталь булмаганнарын да;
- фасадларның төсле чишелеше, шул исәптән декоратив-сәнгати бизәү төрендә;
- гомумкулланыштагы, чикле кулланыштагы җирләрне комплекслы төзекләндерү;
- кондиционерларның тышкы блокларын комплекслы урнаштыру.

Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарындагы төзекләндерү элементларына проект (паспорт) мәдәни мирас объектларын саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтле органнар белән килешенә.

Биләмәне төзекләндерүнең озак вакытлы яки даими кулланылышлы стационар элементлары аларны кулдан күчереп кую мөмкинлеген калдырмыйча, ныгытып урнаштырылырга тиеш.

Төзекләндерү элементларындагы мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасында дәүләт телләре турында закончалык таләпләрен саклап урнаштырылырга тиеш.

Ике яки күбрәк тел кулланылган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше ягыннан охшаш булырга, аңлаешлы итеп эшләнергә тиеш.”

**91**. 170.1 пунктта “һәм транспорт чараларының һәм башка техниканың куеп тору урыннары белән” сүзләрен алып атырга”

**92**. Түбәндәге эчтәлекле 170.5 пункт өстәргә:

“170.5. яшелләндерелгән территорияләрне саклау элементларын, транспорт чаралары кермәслек итеп, 0,5 м биеклектән артмаган декоратив коймалар яки 0,5 м биеклектән артмаган баганалардан урнаштырырга”.

**93**. 171 пунктта “бурычлылар” сүзен алып атырга.

**94**. 171.1 пунктта “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**95**. 171.2 пунктта “тәэмин итеп торырга” сүзен “тәэмин итеп торалар” сүзе белән алыштырырга.

**96**. 171.3 пунктта “тәэмин итәргә” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.

**97**. 171.4 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“171.4. Агачлар яки куаклар утыртуны яки күчереп утыртуны, шулай ук сукмаклар челтәрен, мәйданчыкларны, газоннарның планлаштыруын үзгәртүне җирле үзидарәнең башкарма органнары белән килешенгән проектлар буенча гына башкаралар.”

**98**. 171.5 пунктта:

98.1. “карап тотарга” сүзен “карап тоталар” сүзе белән алыштырырга;

98.2. “җитештерергә” сүзен “җитештерәләр” сүзе белән алыштырырга.

**99**. 172.6 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“172.6. Агачларга һәм башка яшеллекләргә гамаклар, атынгычлар, турниклар, кер киптерү өчен баулар элергә, тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары, күрсәткечләр, афишалар, белдерүләр, агитацион материаллар, техник конструкцияләр, юл хәрәкәтен тәэмин итү чаралары беркетергә, баганаларны, коймаларны, реклама щитларын, электр чыбыкларын, лампаларын, чәнечкеле коймаларны тарттырырга.”

**100**. 172.6 пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 172.6.1 пункты өстәргә:

“172.6.1. Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын, күрсәткечләрне(бирелгән рөхсәт язуысыз, паспортсыз), агитацион материалларны, техник конструкцияләрне, юл хәрәкәтендә катнашучыларны мәгълүмати тәэмин итү чараларын урнаштыру.”

**101**. Түбәндәге эчтәлекле 172.20 һәм 172.21 пунктлары өстәргә:

“172.20. транспорт чараларын, шул исәптән чәчелеп ятучы(төзек булмаганнарын), ел фасылына бәйле булмаган рәвештә, әлеге территорияләрдә мәҗбүри төзекләндерү эшләрен башкару зарурлыгы булу очракларыннан тыш, урманпарк, парк, бакча, бульвар, шәһәр урманнарының яшелләндерелгән территорияләренә кую;

172.21. транспорт чараларын, шул исәптән чәчелеп ятучы(төзек булмаганнарын), ел фасылына бәйле булмаган рәвештә, әлеге территорияләрдә мәҗбүри төзекләндерү эшләрен башкару зарурлыгы булу очракларыннан тыш, дәвалану, балаларның уку һәм фәнни учреждениеләре, җитештерү предприятиеләре, спорт комплекслары һәм торак кварталларының яшелләндерелгән территорияләренә кую;”

**102**. 196.1 пунктта:

102.1. өченче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын куючы хуҗалар аларның тәртиптә булуын тәэмин итәләр, үз вакытында тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларының куелу урыннарын җыештыралар һәм ремонтлыйлар.”

102.2. бишенче абзацта “торгызырга бурычлы” сүзен “торгызалар” сүзе белән алыштырырга.

**103**. 196.3 пунктта “стела” сүзен “күләмле-пространстволы композиция” сүзе белән алыштырырга.

**104**. 196.4.4 пунктта:

104.1. 1 нче пунктчаны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“ –бер керү юлы булганда, бердән күбрәк конструкция”

104.2. 2 нче пунктчада өченче абзацны алып атырга.

104.3. 12 пунктчада “стелалар” сүзен “күләмле-пространстволы композиция” сүзе белән алыштырырга.

104.4. 13 пунктчада “телефон номерларын, сайтларны, электрон почта адресларын” сүзләрен алып атырга;

104.5. түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:

“21) телефон номерларын, сайтларны, электрон почта адресларын күрсәтеп”.

**105**. 196.5.1 пунктта:

105.1. беренче абзацта:

105.1.1. “каркасның” сүзен “беркетү элементларының” сүзләре белән алыштырырга;

105.1.2. “билгеләр һәм беркетү элементларын” сүзен “һәм (яки) билгеләр” сүзе белән алыштырырга;

105.2. 16 пунктчаны түбәндәгечә бәян итәргә:

“16) биналарда, стационар булмаган сәүдә объектларында, фризның төсеннән аерылып торучы фон төсләре кулланып”.

**106**. 196.5.4 пунктның 6 пунктчасында “фонтанда” сүзе алдыннан “вертикаль тәртиптә” сүзе өстәргә.

**107**. 196.5.6 пунктта 3 нче пунктчада:

107.1. “0,3 м” сүзен “0,6 м” сүзе белән алыштырырга;

107.2. “0,2 м” сүзен “0,4 м” сүзе белән алыштырырга.

**108**. 196.5.7. пунктта “стелалалр” сүзен “күләмле- пространстволы композицияләр” сүзе белән алыштырырга.

**109**. 196.5.8 пунктта:

109.1. беренче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Күләмле-пространстволы композиция – шәхси башкаруда, кече( 6,0 метрдан биек булмаган) яки эре (6,0 м дан биегрәк) форматта эшләнгән, фундамент, каркастан торучы, нейтраль төсләрдәге(соры, ачык көрән, графит, кара, көрән һ.б.ш) материал белән тышланган, оешманың кыскача исемен үз эченә алган, 1500 кв.м. дан зуррак мәйданлы массакүләм карау биналары, корылмалары өчен -бренд, аерым басып торучы декоратив-мәгълүмати конструкция,”

109.2. “стелалар” сүзен “күләмле-пространстволы композиция” сүзе белән алыштырырга;

109.3. түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә:

“15) 1500 кв.м. дан зуррак мәйданлы массакүләм карау биналары, корылмалары өчен бренд кулланмыйча”.

**110**. “Гражданнар өчен белдерүләр, мәдәни һәм спорт чаралары афишалары өчен җайланмалар” бүлеген алып атырга.

**111**. 205 пунктта “тәэмин итәргә бурычлылар” сүзен “тәэмин итәләр” сүзе белән алыштырырга.